*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Дөньяда иң кечкенә бәхет – байлык, иң зур бәхет – саулык.* (Мәкаль)
   а) дөньяда
   ә) бәхет
   б) байлык
   в) саулык

2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Сәфәргә чыкканчы, башта юлдаш тап.* (Мәкаль)
   а) сәфәргә
   ә) чыкканчы
   б) башта
   в) юлдаш

3. Архаизмны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) дрон
   ә) куцат
   б) алпавыт
   в) берлән

4. Ясалма нигезле сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кызчык
   ә) көрәк
   б) сөйләде
   в) алмалар

5. Урын рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) әкрен
   ә) шактый
   б) югары
   в) бушка

6. Бәйлекне билгеләгез. **(2 балл)**

а) кебек
ә) дип
б) тик
в) түгел

7. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Ашыккан бер эшне ике эшләр*. (Мәкаль).
а) ашыккан
ә) эшне
б) ике
в) эшләр

8. Кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Күп укыган күп белер. (Мәкаль).
ә) Гыйлем алу – энә белән кое казу. (Мәкаль).
б) Белем – бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы. (Мәкаль).
в) Уку каты булса да, җимеше татлы. (Мәкаль).

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Күп иҗекле сүзләрдә көчлерәк әйтелгән иҗек ________________ иҗек дип атала. Мәгънәләре охшаш сүзләр __________ дип атала. *-дай/-дәй, -ча/-чә* – ______________ ясагыч кушымчалар. Эш яки хәлнең максат яки тиеш булу мәгънәсен белдереп килгән затланышсыз фигыль _______________ дип атала. Татар телендә исем хәбәрләр һәм ___________ хәбәрләр була.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**
*Во дворе стоит ноябрь. По небу летят тяжёлые, серые тучи. Часто идут холодные долгие дожди со снегом. Певчие птицы летят в тёплые края. Утром на земле уже видны первые заморозки.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.
*Чын дуслык ашаганда беленми, эшләгәндә беленә*. (Мәкаль)
2.1. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне языгыз. **(1 балл)**
2.2. Ясалма сүзләрне языгыз. **(3 балл)**
2.3. *Беленә* фигыленең заманын, зат-сан белән төрләнешен языгыз. **(3 балл)**
2.4. Тиңдәш кисәкләрне языгыз. **(1 балл)**
2.5. Җөмлә кисәкләрен билгеләгез. **(4 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 8 җөмлә языгыз. **(15 балл)**